**Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Киртәле авыл җирлегенең Киртәле торак пунктында 2025 елда гражданнарга үзара салым кертү турында гражданнар җыены карары**

**18 .08. 2025** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елгы 131 номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында " 28.07.2004 елгы 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Тәтеш муниципаль районы Киртәле авыл җирлегенең Киртәле торак пунктында гражданнар җыены карар кабул итте:

1. «Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Киртәле авыл җирлегенең Киртәле торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 15.11.2024 № 1, «Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Киртәле авыл җирлегенең Киртәле торак пунктында 2025 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» 15.11.2024 № 2 карарларына үзгәрешләр кертергә.редакция.:

"- Гагарин урамы, Ленин урамы буенча Киртәле торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (смета нигезендә авыл эчендәге юлларны ремонтлау: вак таш, ком сатып алу, нигез әзерләү, ташу, салу, эшләр, хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

- Киртәле торак пунктында урамнарны яктырту җайланмасы (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, урамнарны агымдагы ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү)".

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Киртәле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (https://tetushi.tatarstan.ru/) һәм «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы " нда (https://pravo.tatarstan.ru/) урнаштырырга.

**Җитәкче урынбасары** **С.В. Поселкина**